РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» июня 2025 ел г. Альметьевск № 1541

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Балалар һәм яшьләр эшләре идарәсенә гамәлгә куючының аерым функцияләрен һәм вәкаләтләрен тапшыру турында» 2022 елның 18 июлендәге 1492 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

РФ Бюджет кодексының 38.1 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яшьләр эшләре идарәсе исемен үзгәртү һәм уставын раслау турында» 2024 елның 5 ноябрендәге 3588 номерлы карары, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Креатив Процесслар фабрикасы» яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесен төзү турында» 2024 елның 15 маендагы 1776 номерлы карары нигезендә, Әлмәт муниципаль районы Контроль-хисап палатасының «Әлмәт муниципаль районы муниципаль һәм автоном учреждениеләренә муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр һәм башка максатларга субсидияләр бирү тәртибе турында»аналитик язмасы нигезендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Балалар һәм яшьләр эшләре идарәсенә гамәлгә куючының аерым функцияләрен һәм вәкаләтләрен тапшыру турында» 2022 елның 18 июлендәге 1492 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемендә «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының балалар һәм яшьләр эшләре идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яшьләр эшләре идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

карарның 1 пунктында:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының балалар һәм яшьләр эшләре идарәсенә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яшьләр эшләре идарәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

заказ № 1-851

түбәндәге эчтәлекле алтынчы һәм җиденче абзацлар өстәргә:

«- муниципаль задание үтәлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирү турында килешүләр төзү;

- башка максатларга субсидияләр бирүгә килешүләр төзү, субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен үтәвен тикшереп торуны гамәлгә ашыру, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә»;

карарның 1 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында PRAVO.TATARSTAN.RU урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе Г.М. Хәбутдинова

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«27» июнь 2025 ел №1541
карары белән расланган
1 нче кушымта

Идарәгә буйсынучы учреждениеләрнең исемлеге

Табл. № 1

| № п/п | Учреждение исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. | «Яшьләргә ярдәм итү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 2. | «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 3. | «Әлмәт муниципаль районының «Каенкай» ял-сәламәтләндерү лагере» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 4. | «Креатив процесслар фабрикасы» яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе |

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль
мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптева